

Юлия Алмаметованын Саранскта жомга кон «Святая, как хлеб, деревенька моя» кvргэзмэсе ачылды. Эрьзя музеенда авылга багышланган кvп кенэ фотографиялэр эленгэн иде.
Юлия Алмаметова Мордовиянен Зубово-Поляна районындагы Ширингушиенда туган. Ана дvрт яшь тулгач, эти-эниләре Санкт-Петербургка кvчеп китэлэр. Эмма Юлиянен ин яраткан урыны булып кече Ватаны кала бирэ. Нева елгасы буенда яшэсэ дэ, фотограф Юлия Алмаметова Ширингуши яныннан аккан Вад елгасын беркайчан онытмый. Фоторэсемнэрендэ дэ туган яклары табигате, халкы зур урын алып тора. Бик тэ кызыклы: каралы-аклы фотографиялэрендэ Юлиягэ кеше кvнеленен тирэн почмакларын, кэефен һэм бер-берсе белэн монэсэбэтен кvрэ белэ һэм vзенен тамашачысына да тулысынча житкерерлек итеп тошерэ.
Кvргэзмэнен тантаналы ачышында Юлиягэ кvпторле сораулар бирелэ. Һэм инде зур кызыксындырган сорауларнын берсе – анын шэхси тормышы.  Эти-энисе анын – гади хезмэт иялэре; профессиялэре ижат белэн берничек тэ бэйлэнми. Этисе - Равиль Эхмэтша улы Чукашкин – татар миллэтеннэн. Ул чын ир, «алтын куллы» мастер. Агач белэн бик тэ дус; плотник булып та, столяр булып та хезмэт иткэн. Э энисе - Татьяна Николаевна Батунова - рус миллэтеннэн. Доресрэге, энисе ягыннан Юлия мукшы кызы. Менэ шундый миллэтлэр дуслыгы чагыла бу династиядэ.
Балачакта Юлия Равиль кызы бик тэ фотоальбомнар караргa яраткан, рэсемдэге кешелэр турында сораштыра торган булган. Дуслары белэн туган ягында ялан тэпи йоргэн вакыттан ук аны табигать, тирэ-кvршелэр, кызыклы тарихи мизгеллэр – барысы да кызыксындырган. Мэктэпне тэмамлагач, педагогик белем алып балалар бакчасында рэхэтлэнеп эшлэгэн ул. Шул вакытта vзенен группасындагы балаларны фотога тошерергэ яраткан. Мавыгып, фотограф профессиясе нечкэлеклэрен ойрэнэ ул.
«Алмаметова – это творческий псевдоним, - ди Юля «Известия Мордовии» корреспонденты Мила Мельниковага биргэн интервьюсында, - но не выдуманный. Я взяла фамилию прадедушки по отцовской линии».
Бvген Юлия Алмаметова профессионал буларак фотолар тошерэ, кvргэзмэлэре эшли. Торле теманы яктырта ул vзенен фоторэсемнэрендэ – театр vзенчэлеклэрен, портретлар, шэһэр пейзажлары...һэм башка бик кvп кvренешлэрне тарихи мизгел итэ. Э Ширингуши темасы – кvнеле очен тошерелгэн фотолар. Ин унышлылары белэн тамашачысы белэн уртаклаша. Юлия Алмаметованын кызыклы фотокvргэзмэсен кvрергэ

теләүчеләр, алтынчы декабрьгә кадәр, Эрьзя Музей бинасында тамаша кыла алалар.

**Н.Хәлил**